ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

"Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында" 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (III өлеш); 2009, № 9 – 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре исемлеге үзгәргән очракта, муниципаль район һәм аның составындагы авыл җирлекләре арасында.";

2) 2 статьяның 3 өлешендә:
а) 3 пунктта "Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан" сүзләрен "Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан" сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 пунктта "Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында" сүзләрен "Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында" сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяның 4 өлешендәге беренче абзацында татарча текст үзгәрешсез кала.

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 9-ТРЗ